МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.02.2018 г.Казань № 82

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының вазыйфаи бурычларны үтәгәндә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр кулланыла торган, аңа билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә боерык бирәм:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының вазыйфаи бурычларны үтәгәндә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр кулланыла торган, аңа билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба - Исемлек) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Садыйкова В.Р.):

әлеге боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә тапшырырга;

әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

"Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының вазыйфаи бурычларны үтәгәндә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр кулланыла торган, аңа билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2013 елның 4 июлендәге 188-1л/с номерлы;

"Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 4 июлендәге 188-1л/с номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының вазыйфаи бурычларны үтәгәндә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр кулланыла торган, аңа билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 28 октябрендәге 279-1л/с номерлы.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының 2018
елның «      »   ___________,
_____________________ номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының**
вазыйфаи бурычларны үтәгәндә
дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр кулланыла торган,
аңа билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин
дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары
исемлеге

| Вазыйфалар исемнәре | Саны (берәмлек) | Искәрмә |
|---|---|---|
| **Җитәкчелек** | | |
| Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары - Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры | 1 | |
| Татарстан Республикасы икътисад министрының урынбасары | 4 | |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшләр идарәчесе | 1 | |
| Татарстан Республикасы икътисад министры ярдәмчесе | 1 | |
| **Юридик бүлек** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 | |
| Әйдәүче киңәшче | 1 | |
| **Финанс исәбе һәм хисап бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 | |
| **Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Әйдәүче белгеч | 2 | |
| **Мобилизацион әзерлек һәм гражданнар оборонасы секторы** | | |
| Сектор мөдире | 1 | |
| Әйдәүче киңәшче | 1 | |
| Әйдәүче белгеч | 1 | |

| | | |
|---|---|---|
| **Макроикътисадый фаразлау бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 | |
| **Икътисад тармакларын һәм социаль өлкәне үстерү бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 | |
| **Территориаль үсеш идарәсе** | | |
| Идарә башлыгы | 1 | |
| **Муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 | |
| **Административ реформалар мәсьәләләре идарәсе** | | |
| Идарә башлыгы | 1 | |
| **Дәүләт идарәсен камилләштерү бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| **Оештыру идарәсе** | | |
| Идарә башлыгы | 1 | |
| **Оештыру эше бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| **Мәгълүматлаштыру бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| Әйдәүче белгеч | 1 | |
| **Административ-хуҗалык бүлеге** | | |
| Бүлек башлыгы | 1 | |
| **БАРЛЫГЫ:** | **32** | |